КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 27 апрель г.Казань № 534

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе турында» 2017 ел, 21 сентябрь, 705 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 07 июль, 648 нче, 2022 ел, 14 октябрь, 1100 нче, 2022 ел, 29 декабрь, 1435 нче, 2023 ел, 21 март, 309 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибенә кушымтада:

1.1 пунктның 2 графасына «, кан үзәкләре» сүзләрен өстәргә;

1.2 пунктның 2 графасына «, кан үзәкләре» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган акчалары шул исәптән максатчан тотылырга тиешле керемнәр исемлегенә түбәндәге эчтәлекле 26 пункт өстәргә:

«26. Психик тайпылышлары булган пациентларның хезмәт терапиясе чаралары кысаларында җитештерелгән җиңел сәнәгать товарларын реализацияләүдән алынган керемнәр.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга түләүле хезмәтләр төрләре яктылыгында Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәренең һәм әлеге керемнәрдән (акчасы шул исәптән максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш) хезмәт хакын түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә күләмнәренең план күрсәткечләрен билгеләү турында» 2022 ел, 25 ноябрь, 1261 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының

2022 ел, 29 декабрь, 1439 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 2 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Барлыгы» юлының 4 графасында «5 210 863,0» саннарын «5 205 863,0» саннарына алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы» юлының 4 графасында «3 573 275,0» саннарын «3 568 275,0» саннарына алмаштырырга.

3. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин